| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 март г.Казань № 195

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче; 2020 ел, 6 июль, 555 нче; 2021 ел, 21 апрель, 268 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2022 ел, 12 декабрь, 1316 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1493 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1.1 пунктның таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| « Т/с | Бирелә торган документлар исемлеге | Документ бирүне гамәлгә ашыручы оешма | Документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы | социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасында күрсәтелә |
| 2. | Социаль хезмәтләр күрсәтелүченең шәхесен раслый торган документ | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (Татарстан Республикасында хәрби комиссариатлар), Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгының Консуллык департаменты, граждан хәле актларын теркәү органы, чит ил дәүләтенең компетентлы органнары яки законнар нигезендә шәхесне таныклый торган документны бирүгә вәкаләтле башка органнар | законнар нигезендә |
| 3. | Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтелүченең яшәү урынын раслый торган документ* | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, суд | законнар нигезендә |
| 4. | Законлы вәкилнең шәхесен, статусын һәм вәкаләтләрен таныклый торган документлар** | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, опека һәм попечительлек органы | законнар нигезендә |
| 5. | Инвалидны (инвалид баланы) реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы*** | медик-социаль экспертиза федераль учреждениеләре | инвалидны (инвалид баланы) реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында күрсәтелгән |
| 6. | Авыру тарихыннан (амбулатор картадан) өземтә, профилактик прививкалар (балалар өчен), медицина тикшеренүләре нәтиҗәләре турында белешмә | медицина оешмалары | законнар нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 7. | Яшәү урыны буенча йогышлы авырулар белән контактлар булмау турында белешмә кәгазе | медицина оешмалары | законнар нигезендә |
| 7.1. | Социаль хезмәтләр күрсәтелүченең гаиләсе әгъзасы (Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре, шулай ук югарыда күрсәтелгән гражданнар категорияләренең махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган гаилә | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (Татарстан Республикасында хәрби комиссариатлар), Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе яисә башка вәкаләтле орган | законнар нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | әгъзалары арасыннан, инвалид балалар арасыннан (мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренә кабул иткәндә)) махсус хәрби операциядә катнашуны раслый торган документ | | |
| 8. | Гаиләдә даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ инвалид бала булуга бәйле рәвештә, социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнар арасыннан даими булышлык күрсәтеп торучыга социаль хезмәтмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы**** | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы | социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасында күрсәтелә |
| Социаль-тернәкләндерү бүлекләренә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренә урнашканда, түбәндәгеләр өстәмә тапшырыла: | | | |
| 9. | Гражданның ташламалы категориягә керүен раслый торган билгеләнгән үрнәктәге документ***** | дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органнары, оешмалар һәм комиссияләр | билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелә |
| 10. | Гражданның яшәү урыны буенча аның белән бергә яшүче затлар турында белешмә****** | ******* | 30 дней |
| 11. | Гражданның яшәү урыны буенча бергә яшүче затларны аның гаилә әгъзаларына кертеп карауның хокукый нигезләрен раслый торган документлар күчермәләре****** | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы һәм аның структур бүлекчәләре, граждан хәле актларын теркәү буенча территориаль органнар | законнар нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 12. | Гражданның, аның гаилә әгъзаларының соңгы 12 ай эчендә алынган, акчалата формада алган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бушлай социаль хезмәтләр күрсәтү өчен җан башына уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы карары нигезендә аның җан башына уртача керемен билгеләгәндә исәпкә алына торган һәм социаль хезмәтләр күрсәтүгә түләү күләмен исәпләгәндә кулланыла торган керемнәре булу (булмау) турында документлар (белешмә)****** | керемнәр булу (булмау) турында документлар (белешмә) бирүгә вәкаләтле органнар (оешмалар) | законнар нигезендә |

*Бу Тәртипнең 3.1.3 пунктында каралган очрактан тыш тапшырыла.

**Документлар балигъ булмаганнарны хезмәт күрсәтүгә алганда тапшырыла.

***Документ инвалидларны (инвалид балаларны) хезмәт күрсәтүгә алганда тапшырыла.

****Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртәрәк ярдәм күрсәтү бүлегенә алганда өстәмә тапшырыла.

*****Бу Тәртиптә күрсәтелгән ташламалы категорияләрдәге гражданнарга карата тапшырыла.

******Бу Тәртипнең 3.2.4 пунктындагы «а» – «д» һәм «ж» пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категорияләрдәге гражданнарга карата тапшырылмый.

*******Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза биргәндә бу Тәртипнең 3.2.4 пунктындагы «а» – «д» һәм «ж» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнарның ташламалы категорияләренә кертелмәгән граждан тарафыннан мөстәкыйль рәвештә декларацияләнә.»;

3.3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3. Социаль хезмәтләрне планлаштыру һәм күрсәтү түбәндәге этаплар буенча гамәлгә ашырыла: диагностика, реабилитация чараларын гамәлгә ашыруның индивидуаль планын эшләү, реабилитация чараларын гамәлгә ашыру, аларны үтәү

барышын мониторинглау (күзәтү), тернәкләндерү чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү.

Инвалидлар (инвалид балалар) өчен реабилитация чараларының индивидуаль планы инвалидны (инвалид баланы) реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында күрсәтелгән медик-социаль экспертиза федераль учреждениесе тәкъдимнамәләрен исәпкә алып эшләнә.

Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртәрәк ярдәм күрсәтү бүлегендә иртәрәк ярдәм күрсәтүнең индивидуаль программасын гамәлгә ашыру түбәндәге таләпләр нигезендә башкарыла:

баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) үзенең иртәрәк ярдәм күрсәтелүче баласы белән барлык чараларда (бала адаптацияләнгән хәлләрдән тыш) катнашырга, ә белгеч һәм баланың ата-анасы (законлы вәкиле) баланың максималь мөстәкыйльлеген таләп итә торган дәресләрне уздыру планын килештерергә тиеш;

бала һәм аның гаиләсе белән үзара бәйләнешләр аларның шәхси активлыгына һәм катнашуына нигезләнеп төзелергә тиеш;

иртәрәк ярдәм күрсәтү хезмәтләре максатчан төркем балаларына һәм аларның гаиләләренә иртәрәк ярдәм күрсәтүнең индивидуаль программасыннан, баланың һәм аның гаиләсенең мөмкинлекләреннән һәм әзерлегеннән, баланың яшәү урыныннан һәм шартларыннан чыгып билгеләнгән рәвешләрдә күрсәтелергә тиеш.

Социаль хезмәт күрсәтү кысаларында реабилитация процессын координацияләү максатларында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчегә эксперт советын төзергә тәкъдим ителә, әлеге совет социаль хезмәт күрсәтү кысаларында реабилитация чараларының индивидуаль планын эшли һәм аларны уздыру нәтиҗәлелеген анализлый, социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү срогын озайту зарурлыгын билгели.

Эксперт советының составы һәм эш регламенты социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең боерыгы белән раслана.»;

3.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр (мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү һәм көндезге бүлекләрендә күрсәтелә торган хезмәтләреннән тыш) исемнәре, социаль хезмәтләр күрсәтү тасвирламасы, күләмнәре, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты һәм аның нәтиҗәләрен бәяләү күрсәткечләре әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында китерелде.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.4.1$^1$, 3.4.1$^2$ пунктлар өстәргә:

«3.4.1$^1$. Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү бүлекләрендә социаль хезмәтләрдән файдаланучыга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль

хезмәтләр күрсәтү исеме, тасвирламасы, күләмнәре, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү бүлекләрендә социаль хезмәтләрдән файдаланучының ата-анасына (законлы вәкиленә) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исеме, тасвирламасы, күләмнәре, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү бүлекләрендә, социаль хезмәтләрдән файдаланучыга, социаль хезмәтләрдән файдаланучының ата-анасына (законлы вәкиленә) социаль хезмәтләр күрсәтү исеме, кыска сроклы иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтү күләмнәре әлеге Тәртипнең $2^1$ нче кушымтасында китерелде.

3.4.$1^2$. Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең көндезге бүлегендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исеме, тасвирламасы, күләмнәре әлеге Тәртипнең $2^2$ нче кушымтасында күрсәтелде.»;

3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Социаль хезмәтләр күрсәтү социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә һәм мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә инвалид балалар өчен – 21 эш көненә кадәр, социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә инвалидлар һәм өлкән яшьтәге гражданнар өчен – 15 эш көне, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидлар өчен – 15 эш көне тәшкил итәргә тиеш.

Социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү (мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү һәм көндезге бүлекләрендә социаль хезмәтләр күрсәтүдән тыш) вакыты елына ике тапкыр тәшкил итә.

Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидлар өчен, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә инвалид балалар, психик бозылышы булган һәм тәртибе бозылган, аралашучанлыгы, социаль бәйләнеше бозылган, инвалидлыгы булмаган, сәламәтлегенең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен социаль хезмәт күрсәтү (мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү һәм көндезге бүлекләрендә социаль хезмәтләр күрсәтүдән тыш) социаль хезмәт күрсәтү срогы тәмамлануга кадәр социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә торган биш көннән дә соңга калмыйча бирелгән социаль хезмәтләрдән файдаланучының (аның законлы вәкиленең) тиешле гаризасы нигезендә (әмма социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә торган иң күбе 30 көнгә) озайтыла.

Социаль хезмәт күрсәтү срогын озайту турында карар социаль хезмәтләрдән файдаланучының мотивацион әзерлеге (тернәкләндерү дәресләрендә даими булу, тәкъдимнәрне үтәү) һәм тернәкләндерү чараларын уздыру нәтиҗәсендә уңай динамикасы булганда кимендә социаль хезмәтләр күрсәтү срогы тәмамлану көненә кадәр социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә торган

кимендә өч көн кала кабул ителә. Социаль хезмәт күрсәтү срогын озайту турында кабул ителгән карар хакында социаль хезмәтләрдән файдаланучыга (аның законлы вәкиленә) социаль хезмәт күрсәтү срогын озайту турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче социаль хезмәтләр күрсәтүнең соңгы көнендә социаль хезмәтләрдән файдаланучы (аның законлы вәкиле) белән социаль хезмәтләр күрсәтү срогын үзгәртү өлешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамәгә өстәмә килешү төзи, ул социаль хезмәт күрсәтү вакытын озайту турында кабул ителгән карар нигезендә озайтыла.»;

түбәндәге эчтәлекле $3.4.2^1$, $3.4.2^2$ пунктлар өстәргә:

«$3.4.2^1$. Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү бүлегендә иртә ярдәм хезмәтләрен күрсәтү 6 айдан 12 айга кадәр чорда, иртә ярдәм күрсәтү буенча индивидуаль программаны исәпкә алып, көненә 4 сәгатькә кадәр күләмдә белгечләрнең индивидуаль графигы нигезендә гамәлгә ашырыла. Социаль хезмәт күрсәтүнең срогы балага 4 яше тулганга кадәр озайтылырга мөмкин.

Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү бүлегендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында иртә ярдәм хезмәтләре максатчан төркемдәге балаларга (тормыш эшчәнлеге чикле 0 яшьтән 4 яшькә кадәр балаларга, риск төркемендәге балаларга) һәм аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) күрсәтелә.

$3.4.2^2$. Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең көндезге бүлегендә хезмәт күрсәтү 3 айдан 6 айга кадәрге чорда, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын исәпкә алып, көненә 4 сәгатькә кадәр күләмдә гамәлгә ашырыла.

Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең көндезге бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр максатчан төркемдәге балаларга (тормыш эшчәнлеге чикле 0 яшьтән алып 4 яшькә кадәрге балаларга), инвалид балаларга күрсәтелә.»;

3.4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.5. Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләре тарафыннан социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга түбәндәге очракларда дистанцион багланыш ярдәмендә кайбер социаль хезмәтләр күрсәтелергә мөмкин:

социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы авырганда;

социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучының ата-анасы (законлы вәкиле) авырганда;

Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан йогышлы авырулар таралу белән бәйле имин булмаган санитария-эпидемиология хәленә яисә табигый яки техноген характердагы гадәттән тыш хәл барлыкка килүгә бәйле рәвештә кертелгән махсус эш режимы булганда;

мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү бүлегендә 4 яшькә кадәрге балалар һәм аларның законлы вәкилләре социаль хезмәтләрдән файдаланганда.

Дистанцион багланышлар ярдәмендә социаль хезмәтләр социаль хезмәтләрдән файдаланучының (аның законлы вәкиленең) социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчегә социаль хезмәт күрсәтүгә кергәндә бирелгән социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза нигезендә бирелә.

Дистанцион багланышлар ярдәмендә социаль хезмәтләр мәгълүмат һәм телекоммуникация технологияләрен файдаланып, шул исәптән гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, видеоконференция элемтәсе аша, социаль хезмәтләрдән файдаланучының (аның законлы вәкиленең) социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән элемтәгә керү өчен телефон номерлары (электрон адреслар) һәм башка элемтә чаралары аша күрсәтелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.4.7 пункт өстәргә:

«3.4.7. Бала яшәеше торышының иртә ярдәм күрсәтү буенча индивидуаль программаны эшләү критерийларына туры килүен ачыклаган очракта (әмма баланың яшәеш проблемалары кыска срокллы хезмәтләр күрсәтү шарты белән хәл ителергә мөмкин), иртә ярдәм күрсәтүче оешманың ведомствоара консилиумы карары нигезендә ата-аналарга (законлы вәкилләргә) иртә ярдәм күрсәтү буенча индивидуаль программа төземичә генә кыска сроклы иртә ярдәм хезмәтләре тәкъдим ителергә мөмкин. Кыска сроклы иртә ярдәм хезмәтләре 21 эш көне эчендә ата-аналар (законлы вәкилләр) белән килештерелгән ешлыкта күрсәтелергә тиеш. Аларның гомуми саны иң күбе 10нан артмаска тиеш.

Иртә ярдәм күрсәтү буенча индивидуаль программа төземичә генә кыска сроклы иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтү социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче тарафыннан кабул ителгән карар нигезендә ведомствоара консилиум тарафыннан гадәти кабул итү нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.»;

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы исеменә «(мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү һәм көндезге бүлекләрендә күрсәтелә торган хезмәтләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исемнәре, тасвирламасы, күләмнәре» сүзләреннән соң «(мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү һәм көндезге бүлекләрендә күрсәтелә торган хезмәтләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипкә $2^1$ нче һәм $2^2$ нче кушымталар (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин